Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге составына керүче Әхмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2024 елның 14 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кадер авыл җирлеге Уставы, 2025 елның 14 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Сез 2026 елда Кадер авыл җирлегенең Әхмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге бүлектә укучы студентлардан, I группа инвалидлар, ялгыз өлкәннәрдән һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның гаиләләреннән кала һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләрне хәл итү өчен тотуга ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы элементларын сатып алу һәм урнаштыру);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 154 кеше кертелгән, 90 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен 83 кеше тавыш бирде;

җыенның 7 катнашучысы «юк» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегенең Әхмәт торак пунктында гражданнар җыены үткәнен, халык җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2026 елда Кадер авыл җирлегенең Әхмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге бүлектә укучы студентлардан, I группа инвалидлар, ялгыз өлкәннәрдән һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның гаиләләреннән кала һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы элементларын сатып алу һәм урнаштыру);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру) соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегенең Әхмәт торак пункты территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында (Кадер авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Кадер авыл җирлеге башлыгы** **Л.Н. Барсукова**